СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

23.03.2021 Әгерҗе ш. № 7-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 декабрендәге 19-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен гамәлгә ашыру максатында 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык, салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 14 декабрендәге 19-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә, 8.9.1. статья өстәп, түбәндәге эчтәлекле 8.9.1.12 пункт өстәргә:

«8.9.1.12. Җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләнмәгәндә башкарыла. Күрсәтелгән белешмәләр җирле үзидарә органы тарафыннан ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль рәвештә соратып алына.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының шәһәр төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм элемтә буенча «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Ә.Р.Вәлиев